Татар мәктәбендә укучы балаларга
татар теленнән мәктәп олимпиадасы биремнәренең җаваплары
11 нче сыйныф
2016-2017 уку елы

Максималь балл – *79*

I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. *Фатыйма апаны, күпләрнең сөекле артисткасын, һәр җирдә һәркайчан таныш булмаган кешеләр дә танып, исәнләшергә, елмаеп сәлам бирергә ашыгалар* (Ә.Баянов) җөмләсендә ничә сүз сингармонизм законына буйсынмаган? *(2 балл)*

а) ике сүз;

ә) өч сүз;

б) дүрт сүз;

в) бер сүз.

2. Фразеологизмның мәгънәсе ничек? *(2 балл)*

*Кондырлы кодачасы –*

а) ялкау кеше;

ә) уйчан кеше;

б) үпкәчән кеше;

в) тырыш кеше.

3. Тамырдаш сүзләрдән генә торган төркемне билгеләгез: *(2 балл)*

а) көл, көлдергеч, көләч, көлсу;

ә) маллы, малайлык, малчы, маллык;

б) көндәш, көндәлек, көндез, көнкүреш;

в) очлы, очрау, очсыз, очлаю.

4. Дөрес язылган рәтне билгеләгез: *(2 балл)*

а) ыгы зыгы, өр-яңа, китап кына, чем кара;

ә) моң-зар, ямь-яшел, кил че, бар ләбаса;

б) бик матур, белә бит, беләсеңме, кит сәнә;

в) җете сары, һичбер, кайтсана, бир әле.

5. Сан теркәгеч буларак кулланылган җөмләне билгеләгез: *(2 балл)*

а) Мин эзләгән китап бер җирдә юк.

ә) Бергә укыйбыз, бергә ял итәбез.

б) Күз дә алмыйм: бер гөмбәгә, бер кызларга, бер егетләргә карап алам.

в) Берәр хәбәр ишетәсе килгән иде.

6. Гомум үтәүчеле бер составлы фигыль җөмләне билгеләгез: *(2 балл)*

а) Идел буендагы талларга хәтле яфракларын коеп, сусызлыктан көйрәп утыралар (К.Нәҗми);

ә) Тауга карап тау булып булмый (Мәкаль);

б) Ләкин ул чакта инде миңа бик тә кыен булыр (Г.Рәхим);

в) Сызылып кына таң ата.

7. Иярчен аергыч җөмләне билгеләгез. *(2 балл)*

а) Ни бирсәң, шуны алырсың. (Мәкаль);

ә) Илгә ни булса, безгә шул булыр. (Мәкаль);

б) Нәселе нинди, баласы шундый. (Мәкаль);

в) Елан агу тапкан чәчкәдән бал корты бал табар. (Мәкаль).

8. Җөмләнең төрен билгеләгез. *(2 балл)*

*Үзе усал,*

*үзе болай бердә*

*усал түгел кебек шикелле.* (Х.Такташ)

а) гади җөмлә;

ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә;

б) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә;

в) күп тезмәле кушма җөмлә.

9. Җөмләнең төрен билгеләгез. *(2 балл)*

*Кайнар җилләр исә, ә мин түзәм,*

*Басса да тир бөтен җилкәмне...* (Р.Вәлиев)

а) иярченле кушма җөмлә;

ә) күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

б) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә;

в) катнаш кушма җөмлә.

10. Күп иярченле катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез. *(2 балл)*

*Рәхмәт укыйм бу дөньяга,*

*Минә син булган өчен,*

*Керфегеңә ап-ак, йомшак*

*Энҗе кар кунган өчен...* (Г.Гыйльманов)

а) тиңдәш ияргүле;

ә) тиңдәш түгел иярүле;

б) бер-бер артлы иярүле;

в) берничә төр иярүле.

11. Текстның стиле дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. *(2 балл)*

*Мәскәүдә беренче тапкыр Г.Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының бу сезондагы беренче премьерасы – Флорид Бүләковның “Сөясеңме, сөймисеңме...” спектакле күрсәтеләчәк. Спектакльнең режиссеры – Радик Бариев.*

а) рәсми стиль;

ә) публицистикстиль;

б) хатстиле;

в) матур әдәбият стиле.

12. Тыныш билгеләренең дөрес куелган вариантын билгеләгез. *(2 балл)*

*Аннары Максимов быел бигрәк тә бу соңгы чиректә шактый үзгәрде начар укый башлады* (Х.Сарьян).

а) Аннары Максимов быел – бигрәк тә бу соңгы чиректә – шактый үзгәрде: начар укый башлады.

ә) Аннары Максимов быел, бигрәк тә бу соңгы чиректә шактый үзгәрде: начар укый башлады.

б) Аннары Максимов быел, бигрәк тә бу соңгы чиректә, шактый үзгәрде, начар укый башлады.

в) Аннары Максимов быел, бигрәк тә бу соңгы чиректә, шактый үзгәрде: начар укый башлады.

## II. Теоретик бирем.

Аналитик чаралар һәм аларның үзенчәлекләре турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. *(10 балл)*

## III. Грамматик һәм иҗади бирем. *(45 балл)*

Иртән көлсәң кешедән, кич көләрләр үзеңнән.